ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16 октябрь 2025ел № 8375

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге арендалана торган һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны тормышка ашырганда, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан сатып алына торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләүне өлешләп түләү срогын билгеләү турында» 2024 елның 21 октябрендәге 6911 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге арендалана торган һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны тормышка ашырганда, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан сатып алына торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләүне өлешләп түләү срогын билгеләү турында» 2024 елның 21 октябрендәге 6911 номерлы Карарының 1 пунктына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге арендалана торган һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны тормышка ашырганда, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан сатып алына торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләүне өлешләп түләү срогын күчемсез мөлкәт өчен сигез ел һәм күчемле мөлкәт өчен өч ел итеп билгеләргә.»

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов